КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 6 июнь г.Казань № 526

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарының аерым нигезләмәләрнең гамәлдә булуын туктатып тору турында

Татарстан Республикасында санитария-эпидемиология хәлен һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарының 4 пунктның өченче абзацының, әлеге карарга 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы 1 пунктчасы һәм 2 пунктындагы 1 һәм 4 пунктчалары гамәлдә булуын туктатып торырга.
2. 65 яшьтән өлкәнрәк яшьтәге гражданнарга, йөрәк-кан тамырлары системасының хроник авырулары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына 2 нче кушымтада күрсәтелгән авырулары булган гражданнарга кешеләр күпләп була торган урыннарда булганда сулыш органнарын индивидуаль саклау чараларын (маскаларны, респираторларны) кулланырга тәкъдим итәргә.
3. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин